Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

30 сентябрь 2019 ел №323

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 233 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Әлмәт муниципаль районы муниципаль вазифаларын биләүче затларның хезмәт хакын тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, Әлмәт шәһәр прокурорының 2019 елның 12 сентябрендәге 925 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 11 маендагы «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазифаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» 233 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Үз эшчәнлеген даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затларының, Әлмәт муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт хакы» дип исемләнгән I бүлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы вазифаи затларының, Контроль-хисап палатасы рәисе, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакы һәм түләү тәртибе:

1.1.1. 3 пунктның беренче абзацында «айлык акчалата бүләк түләнә» сүзләреннән соң «айлык акчалата бүләк 2,37 күләмендә» сүзләрен өстәргә»;

1.1.2. 4 пунктның беренче абзацында «айлык акчалата бүләк түләнә» сүзләреннән соң «айлык акчалата бүләк 1,07 күләмендә»;

1.1.3. 5 пунктның беренче абзацында «айлык акчалата бүләк түләнә» сүзләреннән соң «айлык акчалата бүләк 1,07 күләмендә» сүзләрен өстәргә.»;

1.1.4. 6 пунктның беренче абзацында «айлык акчалата бүләк түләнә» сүзләреннән соң «айлык акчалата бүләк 1,07 күләмендә» сүзләрен өстәргә.»;

1.1.5. I бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7. Ай саен бирелә торган акчалата түләүләрнең җыелма күләме муниципаль вазифаны биләүче затның еллык хезмәт хакы фондын хисап елында исәпкә алынган эш вакыты айларына бүлүдән чыгып исәпләнә.».

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2019 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Баһманов И.Р.).

Муниципаль район башлыгы Т.Д. Нагуманов